ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 1017

2018 елның12 декабре

***Постановление*** ***Карар***

Планлаштырылган төзелеш
турындагы белдерүдә күрсәтелгән
шәхси торак төзелеше яки бакча йорты
объектлары параметрларының тәңгәл
килүе турында белдерү җибәрү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын
раслау турында

Россия Федерациясенең 2003елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия

Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 нче номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында”гы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 нче номерлы Карарына таянып, Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 2010 елның 25 ноябрендә кабул ителгән “Чистай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында”гы 1564 нче номерлы Карары нигезендә Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы башкарма комитеты (“Чистай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында”гы 25.11. 2010 елгы1564 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 03.02. 2012 елгы 69 нчы номерлы Карары редакциясендә)

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта нигезендә планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектлары параметрларының тәңгәл килүе һәм җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларын урнаштыру мөмкинлеге яисә планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектлары параметрларының тәңгәл килмәве һәм (яки) җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларын урнаштыру мөмкин булмавы турында белдерү җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентны расларга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны үтәүгә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.Ф.Рәхимовка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов